**Карар**
**Татарстан Республикасы Зәймуниципаль районы Бигеш авыл җирлеге**
**Карман торак пунктында гражданнар җыены карары**

**19.11.2019** **№ 1**

«Россия Федерациясендәҗирлеүзидарәоештыруныңгомумипринципларытурында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлыФедеральзаконның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Карман торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Карман авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
- янгын гидранты урнаштыру;
- буяу сатыпалу һәм зират коймасын буяу;
- торак пункт эчендәге юлларны ремонтлау һәм вак таш җәю.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бигешавылҗирлегебашлыгы____________________ И.Р. Вәлиев